**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** 05.08.2024

Казан ш.

**БОЕРЫК** № 861-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2023 елның 18 сентябрендәге 1084-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Министрлыкның норматив хокукый актны Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2023 елның 18 сентябрендәге 1084-п номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2024 елның 24 июнендәге 701-п номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекнең 1.3 пунктындагы «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яисә җайга салу турында чикләмәләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәвен тәэмин итүдә, коррупциягә каршы тору максатларында алар тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законда,

башка федераль законнарда билгеләнгән бурычлар үтәлешен (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу) тәэмин итүдә;»

III бүлектә:

3.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге «е» пунктчасы белән тулыландырырга:

«е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга комачаулаучы, аңа бәйле булмаган шартлар барлыкка килүе турында хәбәр итүе.»;

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән белдерүләр Министрлыкның кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы булган вазыйфаи заты тарафыннан карала, ул белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмә әзерли.»;

3.4.2 пунктында «3.1 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен «3.1 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга;

3.4.3 пунктта:

«а» пунктчасында «3.1 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен «3.1 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга;

«в» пунктчасында «3.1 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен «3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләренә, «3.13, 3.15.1, 3.18 пунктлары нигезендә» сүзләрен «3.13, 3.15.1, 3.18, 3.19 пунктлары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга»;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән белдерүләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планга кертелгән) утырышында карала.»;

3.8 пунктта «3.1 пунктның «б» пунктчасы белән» сүзләрен «3.1 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

3.8.1 пунктның «а» пунктчасында «3.1 пунктның» б « пунктчасы белән» сүзләрен «3.1 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

3.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын таныйрга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын таныйрга.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча һәм, моңа нигезләр булган очракта, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11-3.15.1, 3.17-3.19 пунктларында каралганнан башкачарак карар кабул итә ала. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.»

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр А.В. Шадриков